Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор авылында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» март, 2024 ел. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 2023 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор торак пунктында гражданнар җыелышы №2 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 нче пунктта "1400 сум"дигән сүзтезмәне "600 сум"га алмаштырырга;

2. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кулланырга:

Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:

- Ю.Гагарин урамында асфальт өслек җәю;

-Ю.Гагарин һәм М.Җәлил урамнары буйлап вак таш җәю.

Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау:

-М.Җәлил урамындагы елга аша җәяүлеләр күперен ремонтлау».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Салихҗанов Р.Х.